Фәтхуллова Кадрия Сөнгать кызы, педагогика фәннәре кандидаты, доцент, Казан федераль университеты, Казан шәһәре
420140 г.Казань, ул Завойского, д.3, кв.119; e-mail kadria.kgu@mail.ru
тел. 89276760260

Татар теленә өйрәтү методикасын камилләштерү мәсьәләләре

Бүгенге көндә халыклар үзара тыгыз бәйләнештә яшиләр, бер-берсе белән хезмәттәшлек итәләр. Дөнья зур бер фәнни-икътисади комплексны хәтерләтә. Ел саен дистәләгән халыкара форумнар, симпозиумнар, фәнни-гамәли конференцияләр, дәүләтара очрашулар үткәрелә һәм аларда, төрле милләт вәкилләре катнашып, тел ярдәмендә төрле мәсьәләрне хәл итәләр. Тел төп аралашу чарасы буларак кешеләргә хезмәт итсә, сөйләм төп аралашу ысулы булып тора. Шунлыктан бүгенге көндә һәрбер телне мәдәниятара һәм шәхесара аралашу-аңлашу чарасы буларак укыту иң мөһим мәсьәләләрдән санала.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 нче маддәсе һәм «Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы» Закон нигезендә татар һәм рус телләре – тигез хокуклы дәүләт телләре. Күп милләтле Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәшкил итә. Татарстанда татар теле барлык урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләрендә төп укыту фәннәренең берсе булып тора, күп кенә югары уку йортларында да булачак белгечләр рус теле белән беррәттән татар теленнән белемнәрен тирәнәйтәләр. Республикабызда телләр сәясәтенең киләчәктә үсеш алуы, татар теленең гамәли һәм интеллектуаль тормышта урын алу-алмавы аны мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укыту дәрәҗәсенә дә бәйле. Мондый шартларда татар теленә өйрәтү методикасын камилләштерү житди бурычларның берсе булып тора. Татар телен аралашу чарасы

буларак укыту өчен, иң нәтиҗәле методик алымнарны куллану, информацион-коммуникатив технологияләрдән киң файдалану аеруча зур әһәмияткә ия.

Соңгы елларда республикабызда әлеге өлкәдә җитди адымнар ясалды: татар теленә өйрәтү методикасының үткәнен һәм бүгенгесен яктыртуга багышланган фәнни монографияләр дөнья күрде; мәктәп программалары һәм дәреслекләре яңартылды; укытучылар өчен методик кулланмалар, уку-укыту ярдәмлекләре һәм дидактик әсбаплар, төрле сүзлекләр төзеп бастырылды, электрон дәреслекләр, аудиокурслар, интерактив тестлар эшләнде һәм укыту практикасында киң кулланыла башлады. Татар теленә өйрәтүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләренә багышланган фәнни конференцияләр үткәрелеп тора, шушы өлкәдәге алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу һәм аны тарату эше дә игътибардан читтә калмый. Димәк, бай тарихка ия булган татар лингвометодикасы заман таләпәреннән чыгып үсеш ала, үзгәрә һәм камилләшә дип әйтә алабыз.

Хәзерге вакытта мәктәпләрдә татар телен аралашу чарасы буларак укыту, шулай ук тел ярдәмендә укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, аларның коммуникатив культурасын формалаштыру бурычы куела. Татар телен гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә, укучылар көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия булырга тиешләр.

Татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә, шулай ук башка миләттән булган укучыларны татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләренә якынайта, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, толерантлык кебек универсаль күнекмәләр булдыруга этәргеч ясый. Федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә татар теленә өйрәтүнең төп максатлары түбәндәгечә билгеләнә: укучыларның аралашу даирәсен,

тормыштагы аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) буенча аларда коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы) формалаштыру; укучының танып белү, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү; татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү; укучыларны мәдәниятара диалогка тарту; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру.

Лингвометодикада коммуникатив компетенциянең берничә төре билгеләнгән: лингвистик, социолингвистик, дискурсив, стратегик, социаль-мәдәни, социаль компетенцияләр [2: 9]. Татар телен коммуникатив нигездә укыту, беренчедән, балаларда *тел компетенциясе* булдыруга китерә, чөнки алар, тел берәмлекләрен гамәли үзләштереп, сөйләмдә кулланырга күнегәләр; икенчедән, аларның *сөйләм компетенциясе* үсеш ала, чөнки тел аралашу аша үзләштерелә; өченчедән, тел һәм сөйләм берәмлекләре аша татар дөньясы турындагы мәгълүматны үзләштереп, алар *социаль-мәдәни компетенциягә* ия булалар.

Хәзерге вакытта телгә өйрәтүнең иң заманча юнәлешләре булып коммуникатив һәм эшчәнлекле методлар санала. Татар теленә өйрәтүнең төп принциплары шушы юнәлешләрнең нигезен тәшкил итәләр. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: коммуникативлык принцибы (телгә өйрәтү шартларын тормышта телне куллану шартларына якынайту); индивидуальләштерү принцибы (укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру); телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы (аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе); телне функциональ төстә өйрәнү принцибы (лексик-грамматик материалның коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм кулланылыш ешлыгыннан чыгып билгеләнүе); ана теле

үзенчәлекләрен исәпкә алу принцибы (балаларның ана теленнән белемнәренә таяну һәм аның аермалы якларын исәпкә алу). Моннан тыш, укыту процессында сөйләм эшчәнлеге төрләрен үзара бәйләнештә үзләштерү, аңлылык, аңлаешлылык, күрсәтмәлелек принциплары да истә тотыла.

Федераль дәүләт белем бирү стандартыннан чыгып, татар теленә өйрәтүнең әһәмиятле бурычларын түбәндәгечә билгелиләр:

– милләтләр, мәдәниятләр төрлелегенә карамастан, дөньяны бердәм һәм бербөтен итеп кабул итү нигезендә шәхесләрнең гражданлык тиңдәшлеген формалаштыру;

– кешеләргә карата игелеклелек, ышаныч һәм игътибарлылык, ярдәм күрсәтергә әзер булу, ихтирам, әңгәмәдәшне тыңлый һәм ишетә белү, кешеләрнең үз фикеренә хокукы барлыгын таный белү нигезендә аралашу һәм хезмәттәшлек итү өчен, психологик шартлар формалаштыру;

– әхлаклылык һәм гуманизм, гаилә һәм мәктәп, коллектив һәм иҗтимагый кыйммәтләрне хөрмәт итү һәм аларны үтәүгә омтылу, этик һәм эстетик хисләр формалаштыру нигезендә шәхеснең кыйммәти-мәгънәви даирәсен үстерү;

– үзлегеңнән белемеңне арттыру һәм үз-үзеңне тәрбияләү нигезендә, үз эшчәнлегеңне оештыра алу осталыгын булдыру;

– үз-үзен актуальләштерү шарты буларак, шәхеснең мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын үстерү.

Татар теленә өйрәтүнең төп эчтәлегенә килгәндә, ул фонетик, лексик, грамматик белемнәрне гамәли үзләштерүдән; татар халкының милли-мәдәни үзенчәлекләрен һәм сөйләм этикеты үрнәкләрен истә тотып, телдән яки язмача аралаша белү, диалогик һәм монологик сөйләмне логик яктан эзлекле итеп оештыра алу, әңгәмә барышында тел “кытлыгын” җиңеп чыгу, татар телендәге мәгълүматны сәнгатьле итеп һәм аңлап укый белү күнекмәләрен үстерүдән гыйбарәт.

Алга таба хәл ителәсе актуаль методик мәсьәләләргә килгәндә, безнең карашка, иң әһәмиятлесе – укучыларның татар телен белү дәрәҗәләрен тикшерү системасын заман таләпләренә туры китереп яңарту, чөнки тикшерү-бәяләү эшләре белем бирү процессының мөһим бер өлешен тәшкил итә. Педагогик тикшерү билгеле бер дидактик функцияләрне үти: *өйрәтү функциясе* (татар телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү); *диагностик функция* (укучыларның әзерлек дәрәҗәсендәге кимчелекләрне ачыклау һәм аларны киметү, укыту процессын камилләштерүгә юнәлтелгән карарлар кабул итү); *тәрбияви функция* (укучыларның үзтикшерү һәм үзбәяләү күнекмәләрен активлаштыру, белем алуга өстәмә этәргеч булдыру); *гомумиләштерү функциясе, прогностик функция* һ.б. [3: 26]. Хәзерге вакытта лингводидактикада күп төрле тикшерү алымнары кулланыла, яңа технологияләр гамәлгә кертелә. Шуларның иң мөһимнәре: 11 нче сыйныфта татар теленнән Бердәм республика имтиханын (БРИ) үткәрү; 9 нчы сыйныфны тәмамлаучы укучылар өчен татар теленнән яңа формада дәүләт (йомгаклау) аттестациясен уздыру. Әлеге тикшерү эшләре укучыларның коммуникатив күнекмәләрен объектив рәвештә бәяләргә, уку-укытуның нәтиҗәлелеген тулырак күзалларга мөмкинлекләр бирә. Тикшерү барышында балаларның белем дәрәҗәсе белән беррәттән укытучының методик эшчәнлеге дә сынала, кулланыла торган укыту чараларының ни дәрәҗәдә уңышлы булуы да ачык күренә.

Билгеле булганча, чит телләргә өйрәтү методикасында укучыларның тел белүләрен өч дәрәҗәгә бүлеп бәялиләр: 1) телне элементар белү дәрәҗәсе (*A*); 2) телне мөстәкыйль рәвештә куллана алу дәрәҗәсе (*B*); 3) телне иркле рәвештә куллана алу дәрәҗәсе (*C*). Аларның һәрберсе, үз чиратында, тагын икегә бүленә, һәм барлыгы алты дәрәҗә күрсәтелә (*A1, A2; B1, B2; C1, C2*) . Әлеге концепция авторлары әйтүенчә, теге яки бу телне өйрәнүчеләрнең белем дәрәҗәләре халыкара стандартлар нигезендә тикшерелергә тиеш. Шулай эшләгәндә генә, төрле урыннарда, төрле дәреслекләр белән телне

өйрәнүчеләрнең белем дәрәҗәләренә объектив бәя биреп була [1]. Димәк, татар теленә өйрәтүдә чит телләр укыту тәҗрибәсенә таянып төзелгән укыту чаралары булдыру һәм аларны гамәлгә кертү, тикшерү-бәяләү материалларын халыкара стандартларга яраклаштыру зур әһәмияткә ия.

Йомгак ясап әйткәндә, бүгенге көндә татар теленә өйрәтү өлкәсендә фәнни-методик эзләнүләр һәм тикшеренүләр дәвам итә, укыту системасының уңышлы һәм җитешсез яклары даими күзәтелеп бара, яңадан-яңа юнәлешләр, информацион-коммуникатив технологияләр тәкъдим ителә. Шуңа бәйле рәвештә һәр укытучы заманча алымнар куллануга, методик осталыгын һәм иҗади активлыгын арттыру, гамәли эшчәнлеген камилләштерүгә омтылса, моның белән берр әттән белем бирү өлкәсендәге үзгәрешләрне алдан тоеп эш итсә, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында татар теленә өйрәтүнең сыйфатын яхшыртуга, тагын да югарырак нәтиҗәләргә ирешеп булыр дип ышанабыз. Шулай эшләгәндә генә, һәрберебез татар теленә өйрәтү методикасын үстерүгә, аны камилләштерүгә үз өлешен кертә ала.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


1. Общеевропейские компетенции владения иностранным языком: Изучение, обучение, оценка. – М.: МГЛУ, 2005. – 247 с.
2. Соловова Е.Н. Методика обучения иностранным языкам: Базовый курс лекций. – 2-е изд. – М.: Просвещение, 2003. – 239 с.
3. Тестирование в обучении русскому языку как иностранному: современное состояние и перспективы /По ред. Т.М.Балыхиной. – М.: МГУП, 2003. – 189 с.